# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында" Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында" 2005 елның 30 декабрендәге 138-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2007, № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 1, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 12 (I өлеш), 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"1. Россия Федерациясе Торак кодексының 159 статьясындагы 2 өлешенең 1 – 3 пунктларында күрсәтелгән затлар өчен торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр бәясенең төбәк стандарты күләме төзекләндерү дәрәҗәсе, конструктив һәм техник параметрлары муниципаль берәмлектәге уртача шартларга туры килә торган күпфатирлы йортлардагы торак урыннарында социаль наем шартнамәләре буенча яши торган яллаучыларның торак урыныннан файдалануы өчен түләү (наем өчен түләү) күләменнән, бу яллаучылар өчен торак урынын карап тотуга һәм ремонт ясауга түләү күләмен исәпләп чыгару өчен кулланыла торган бәяләр күләменнән, коммуналь хезмәт күрсәтүләрне куллануның бу яллаучылар өчен коммуналь хезмәт күрсәтүләргә түләү күләмен исәпләп чыгару өчен кулланыла торган бәяләреннән, тарифларыннан һәм нормативларыннан чыгып билгеләнә. Торак урыннары милекчеләре өчен торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр бәясенең төбәк стандарты күләме бу яллаучылар өчен торак урынын карап тотуга һәм ремонт ясауга түләү күләмен исәпләп чыгару өчен кулланыла торган бәяләр күләменнән, капиталь ремонт ясауга кертемнең минималь күләменнән (Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә капиталь ремонт ясауга кертемнәр түләгән очракта), коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен кирәкле чималга бәяләрдән, тарифлардан һәм бу

яллаучылар өчен коммуналь хезмәт күрсәтүләргә түләү күләмен исәпләп чыгару өчен кулланыла торган коммуналь хезмәт күрсәтүләрне куллану нормативларыннан чыгып билгеләнә.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.




Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 13 апреле
№ 30-ТРЗ